**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы № 108 «07» сентябрь 2018 ел

Референдум уздыруны инициацияләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 12 статьясы нигезендә,

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

“2019 елда үзара салым кертүгә Әлкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 250 сум күләмендә, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү өчен юнәлтергә Сез ризамы:

1) ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;

4) һәйкәлне төзекләндерү;

5) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:

Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стенды: ТР, Азнакай районы, Әлкәй авылы, Совет бистәсе, 4а йорт, Әлкәй авылы китапханәсе, 34 йорт, Совет урамы, 2а йорт мәгълүмат стенды, Совет ур.

- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

Рәис С.З.Зиннурова